**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ КУТЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул. Клубная, д. 1а, с. Кутема,
Черемшанский район, 423112

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**КҮТӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

Клуб урамы, 1- нче «а» йорт, Кутәмә
авылы,
Чирмешән районы, 423112

тел./факс +8(84396)
4-30-88
email:Kut.Cmn2@tatar.ru

№19 18 февраль 2026 ел

**Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Күтәмә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районының Күтәмә авыл
җирлеге Советының аерым карарларының
үз көчләрен югалтуын тану турында**

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

**1.** Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлеге Советының түбәндәге аерым карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибен раслау хакында» 2017 елның 08 августындагы 62 номерлы.
- «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан

Республикасы Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибен раслау хакында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлеге Советының 2017 елның 08 августындагы 62 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2022 елның 18 маендагы 56 номерлы.

**2.** Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

**Күтәмә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **О.Н. Сайгушева**